**СОВЕТ ЕГОРЬЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422621 д.Каипы,
ул. Центральная, д.50
тел: 3-36-19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЕГОРЬЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**
422621 Каип авылы,
Эзэк урамы, 50 нчы йорт,
тел: 3-36-19

---

**55.2номер** **2019елның 16 ноябре**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге составына керүче Егорьево торак пунктындагы гражданнар җыены карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Егорьево авыл җирлеге составына керүче Егорьево гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге составына керүче Егорьево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча урындагы мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Егорьево торак пунктында су башнясын ремонтлау.

3. Әлеге карарны Егорьево авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә: һәм http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче:_________________ Хамиуллин Р.З.

Башлык - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы-
Егорьево авыл җирлеге Советы рәисе _________________ Хамиуллин Р.З.